**ПОСЕЛКОВЫЙ СОВЕТ**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ**
**ПОСЕЛОК ГОРОДСКОГО ТИПА**
**ТЕНИШЕВО**
**КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

---

# КАРАР

11.09.2017ел. № 61-рс

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы»муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын эшләү турында

Россия Федерациясенең 29.12.2004 № 190-ФЗ шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 Федераль законы таләпләре нигезендә, « Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Территориянең тотрыклы үсешен, инженер, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерү максатларында,, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын (алга таба генераль план проектын) Кама Тамагы муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасы һәм җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында эшләргә.

2. Генераль план проектын эшләүгә техник (шәһәр төзелеше) биремен (1 нче кушымта) раслаго.

3. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы»муниципаль берәмлеге башкарма комитеты:
- күрсәтелгән техник (шәһәр төзелеше) биреме нигезендә генераль план проектын эшләү өчен чыганак мәгълүматлар әзерләүне тәэмин итәргә;

- генераль план проектын әзерләү буенча дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, кызыксынган физик һәм юридик затлар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм карауны тәэмин итү.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т. п., Ленин ур., 8 йорт; Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Г. т. п. Тенишево, Пионерская ур., 18.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы
поселогы" муниципаль берәмлеге башлыгы И.Т.Гыйниятов